**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 22 маендагы 1756 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 декабрендәге 4197 номерлы «“2026-2028 елларга «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексы сегментын төзү һәм үстерү” муниципаль программасын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 декабрендәге 4797 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 декабрендәге 5-4 номерлы “2026 елга һәм 2027 һәм 2028 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында”гы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләп чыгару, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары таләпләрен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 декабрендәге 4197 номерлы «“2026-2028 елларга «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексы сегментын төзү һәм үстерү” муниципаль программасын раслау турында»гы карарына, 1 номерлы кушымтаны әлеге карар кушымтасы нигезендәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  22 маендагы
1756 номерлы карарына
кушымта

**«2026-2028 елларга “Имин шәһәр” аппарат-программа комплексы сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасы**

**Муниципаль программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | «2026-2028 елларга “Имин шәһәр” аппарат-программа комплексы сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе |
| Программаны төп эшләүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе |
| Программаның төп башкаручылары | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе<br>«Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – Телекоммуникация технологияләре департаменты) |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты – җәмәгать куркынычсызлыгын, хокук тәртибен һәм яшәү тирәлегенең куркынычсызлыгын арттыру.<br>Программаның бурычы – муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында, Казан шәһәренең җәмәгать киңлекләрендә, паркларда һәм скверларда, җәмәгать фикерен белдерү урыннарында куркынычсызлык системаларын оештырганда заманча мәгълүмат технологияләрен кертү |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2026-2028 еллар; Программаны гамәлгә ашыру этапларга бүленми |
| Ярдәмче | – |

<table>
<tr><td>программалар исемлеге</td><td></td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 883 598,4 мең сум тәшкил итә, шулардан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән – 883 598,4 мең сум.
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Статья</th><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th></tr>
<tr><td rowspan="6">2026</td><td>0113</td><td>74 106,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0707</td><td>12 471</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0709</td><td>202 730,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0804</td><td>38 702,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>1103</td><td>15 875,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>-</td><td>343 885,2</td><td>-</td></tr>
<tr><td rowspan="6">2027</td><td>0113</td><td>11 693,8</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0707</td><td>12 471</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0709</td><td>202 730,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0804</td><td>27 086,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>1103</td><td>15 875,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>-</td><td>269 856,6</td><td>-</td></tr>
<tr><td rowspan="6">2028</td><td>0113</td><td>11 693,8</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0707</td><td>12 471</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0709</td><td>202 730,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>0804</td><td>27 086,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>1103</td><td>15 875,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>-</td><td>269 856,6</td><td>-</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>-</td><td>883 598,4</td><td>-</td></tr>
</table>
Искәрмә. Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә. Аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>Программаны гамәлгә ашыру 2028 ел ахырына түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>– муниципаль милектәге социаль өлкә объектларын 98 процентка кадәр видеокүзәтү һәм эвакуация белән идарә итүнең хәбәр итү системалары белән тәэмин итәргә (ихтыяҗ буенча);<br>– видеокүзәтү системалары мәгълүматлары урнаштырылган муниципаль социаль өлкә объектларының гомуми саныннан видеокүзәтү системаларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау белән тәэмин ителгән социаль өлкә объектлары өлешен</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | 100 процентка кадәр арттырырга;<br>– эвакуация белән идарә итүнең хәбәр итү системаларына хезмәт күрсәтү һәм автомат янгын сигнализацияләрен ремонтлау белән тәэмин ителгән социаль өлкә объектлары өлешен әлеге системалар урнаштырылган муниципаль социаль өлкә объектларының гомуми санына карата 100 процентка кадәр арттырырга;<br>– хәбәрләр тапшыру радиосистемаларының объект станцияләре урнаштырылган муниципаль социаль өлкә объектларының гомуми саныннан мондый объект станцияләренә хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау белән колачланган социаль өлкә объектларының өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>– пульт ярдәмендә сак урнаштырылган муниципаль социаль өлкә объектларының гомуми саныннан пульт ярдәмендә сак системасына хезмәт күрсәтү һәм ремонт белән тәэмин ителгән социаль өлкә объектлары өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>– сак сигнализациясенең объектлы системаларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау белән колачланган социаль өлкә объектларының өлешен әлеге системалар урнаштырылган муниципаль социаль өлкә объектларының гомуми санына карата 100 процентка кадәр җиткерергә;<br>– гадәттән тыш хәлләр вакытында тавыш белән хәбәр итүнең объектлы системаларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау белән колачлаган социаль өлкә объектларының өлешен әлеге системалар урнаштырылган муниципаль социаль өлкә объектларының гомуми санына карата 100 процентка кадәр җиткерергә;<br>– контроль һәм файдалану мөмкинлеге белән идарә итү системалары белән җиһазландырылган муниципаль социаль өлкә объектларының өлешен 98 процентка кадәр җиткерергә; |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы

Әлеге Программа Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 2-12 номерлы карары белән расланган 2030 елга кадәр Казан шәһәрен социаль-икътисади яктан үстерү стратегиясен үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы нигезендә эшләнде.

Казан шәһәре, шәһәр инфраструктурасы белән идарә итүгә заманча чишелешләр кертеп, инновацияләргә тотрыклы бирелгәнлеген күрсәтә. Казан шәһәре Башкарма комитеты муниципаль идарәнең ачыклыгын, нәтиҗәлелеген һәм оперативлыгын күтәрү өчен цифрлы инструментларны актив файдалана, халыкның реаль ихтыяҗларына һәм уңайлы шәһәр мохите булдыруга йөз тота.

Заманча технологияләрне куллану шәһәрнең тотрыклы үсешенә ирешү өчен кирәкле шарт булып тора. Заманча технологияләрнең күптөрлелеге һәм креативлыгы ресурсларны сак тоту, гадел нигездә тоткарлыксыз мәгълүмат алмашу һәм шәһәрдә эшләүнең нәтиҗәлерәк ысулларын булдыру өчен машиналар һәм кешеләр арасында коммуникацияне җиңеләйтү өчен гаять зур потенциал барлыгы турында сөйли. Җирле үзидарә органнарының һәм гражданнарның үзара хезмәттәшлеге аеруча әһәмиятле була башлый. Бүген муниципаль бергәлекнең, җирле хакимият органнарының, актив гражданнарның төбәктә бара торган идарә итүдәге, технологик, мәгълүмати процессларга җәлеп ителүе мөһим. Муниципаль идарәдә цифрлы технологияләр ресурсларны оператив рәвештә һәм дөрес итеп исәпкә алырга мөмкинлек бирәчәк, кабул ителә торган карарларның нәтиҗәлелеген һәм планлаштыруның төгәллеген арттыра.

Программа куркынычсызлык өлкәсендә яңа цифрлы чишелешләр кертүне системалаштыруга юнәлтелгән һәм шәһәр мохитенең сыйфатын күтәрүгә, уңайлы һәм имин яшәү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән. Куркынычсызлык хәзерге шәһәр мохитенең төп элементы булып тора. Шуңа бәйле рәвештә күпфатирлы йортларны, җәмәгать урыннарын һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарны видеокүзәтү системалары белән җиһазлау эшен дәвам итәргә кирәк.

Социаль инфраструктура объектларының куркынычсызлыгына аерым игътибар бирү таләп ителә. Казанда 922 социаль инфраструктура объекты бар – муниципаль мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт һәм физик культура учреждениеләре, шул исәптән аларның филиаллары һәм бүлекчәләре: 394 балалар бакчасы, 204 мәктәп, 51 өстәмә белем бирү объекты, 39 спорт

объекты, 108 мәдәният объекты, 37 яшүсмерләр һәм яшьләр сәясәте объекты, 11 балаларны сәламәтләндерү лагере, шулай ук 28 парк һәм сквер.

Социаль инфраструктура объектларын видеокүзәтү системалары, автомат сак-янгын сигнализациясе, тревога сигнализациясе төймәләре, хәбәр итү системалары белән тулысынча колачлауны оештыру һәм барлык системаларның сыйфатлы эшләвен тәэмин итү – Программаның өстенлекле юнәлеше булып тора.

## II. Гамәлгә ашыру вакытын күрсәтеп, Программаның максатлары һәм бурычлары, чаралар исемлеге һәм аларның кыскача тасвирламасы

Программа җәмәгать куркынычсызлыгын, хокук тәртибен һәм яшәү тирәлегенең куркынычсызлыгын арттыруга юнәлтелгән чаралар комплексын үз эченә ала.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләне хәл итү кирәк: муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында, Казан шәһәренең иҗтимагый киңлекләрендә, паркларда һәм скверларда, җәмәгать фикерен белдерү урыннарында куркынычсызлык системаларын оештырганда заманча мәгълүмат технологияләрен кертү.

Куйган бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән төп чаралар:

1. Җәмәгать киңлекләрендә, паркларда, скверларда һәм җәмәгатьчелек фикерен белдерү урыннарында видеокүзәтү системасын үстерү һәм куркынычсызлыкны арттыру.

Чараны гамәлгә ашыру кысаларында Программаны башкаручы «Телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе оператив идарәсенә җәмәгать киңлекләрендә, паркларда һәм скверларда, җәмәгатьчелек фикерен белдерү урыннарында урнаштырылган видеокүзәтү системалары, эвакуация белән идарә итүнең хәбәр итү системаларының (килешү буенча) 98 процентган да ким булмаган өлешен тапшыру планлаштырыла. Техник яктан хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау Программаны гамәлгә ашыруның барлык срокларында күрсәтелгән дәрәҗәдә башкарылачак.–

2. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында видеокүзәтүнең үсеше.

Чара, расланган иминлек паспортлары нигезендә, социаль өлкә объектларын видеокүзәтү системалары белән тәэмин итүдән, муниципаль контрактларны үтәү кысаларында, видеокүзәтү системаларының эшчәнлеген

мониторинглауны оештыру, белешмәләр тапшыру каналлары булганда – кызыксынучы оешмаларга, хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнарына билгеләнгән тәртиптә видеокүзәтү камераларыннан агымлы мәгълүматны тапшырудан, видеокүзәтү системаларын булган мәгълүмат ресурслары һәм аппарат-программа чаралары белән интеграцияләнүеннән гыйбарәт.

3. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында куркынычсызлыкны арттыру.

Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү системалары составына (бирелгән куркынычлылык категориясенә бәйле рәвештә) автоматик янгын сигнализацияләре, янгын вакытында хәбәр итү һәм кешеләрне эвакуацияләү белән идарә итү системалары, рөхсәтне контрольдә тоту һәм аның белән идарә итү системалары, хәвефле хәбәрләр тапшыруның объектлы станцияләре, хәвефле сигнализация төймәләре, сак сигнализациясе керә.

4. Мәгълүмат чыганакларының һәм куркынычсызлык системаларының техника хәлен мониторинглау, муниципаль милектә булган социаль өлкә объектларында ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру.

Чара кысаларында видеокүзәтү системаларында видеоаналитика, видеокүзәтү системаларының эшкә сәләтлелеген мониторинглау, Казан шәһәрендә урнаштырылган видеокүзәтү камераларын интеграцияләү, төрле министрлыклар һәм ведомстволар өчен камералар белән идарә итүгә рөхсәт итү сервисы тәэмин ителә.

Чараны үтәү социаль өлкә объектларында террорчылыктан саклану дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм итәчәк һәм Казан шәһәре халкына мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәләрендә хезмәт күрсәтү өчен уңайлырак шартлар тудыруга ярдәм итәчәк.

5. Казан шәһәре Башкарма комитетының административ биналарының иминлек системаларын оештыру һәм аларга техник хезмәт күрсәтү

Чара кысаларында Казан шәһәре Башкарма комитетының административ биналарында куркынычсызлык системаларының техник торышына аудит үткәрү, кисәтү характерында техник хезмәт күрсәтү планын эшләү, җиһазларны модернизацияләү һәм яңарту тәэмин ителә.

Чараны үтәү җиһазлар белән ерактан торып мониторинглау һәм идарә итү мөмкинлеген тәэмин итә, бу барлыкка килә торган проблемаларга оператив җавап бирергә, техник хезмәт күрсәтү тоткарлыкларын юкка чыгарырга, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының административ биналарында гомуми

иминлек дәрәҗәсен һәм эш процессларының нәтиҗәлелеген күтәрергә ярдәм итә.

6. «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

Төп чара «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенең оператив идарә итү хокукында үзенә беркетелгән биналарын һәм мөлкәтен карап тотуны, төп чараларны, шул исәптән җиһазларны сатып алуны, хезмәткәрләрнең хезмәт хакын, элемтә хезмәтләрен, мәгълүматны тапшыру хезмәтләрен, транспорт хезмәтләрен, җиһазларга техник хезмәт күрсәтүне һәм аларны карап тотуны үз эченә ала.

«Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесендә штат расписаниесе һәм вазифаи инструкцияләр нигезендә, эшкә алу мөмкинлегеннән чыгып, потенциаль кандидатларны сайлап алу һәм аларга кадрлар аудиты үткәрү буенча эшләр уздыру күздә тотыла.

«Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесендә кадрлар сәясәтен гамәлгә ашырганда хезмәт дисциплинасын үтәүгә, коррупциягә каршы көрәшкә, мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга һәм хезмәтне саклауны тәэмин итүгә аерым игътибар биреләчәк.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенең кадрлар белән тәэмин ителешен һәм матди-техник тәэмин ителешен штат расписаниесенең 100 проценты дәрәҗәсендә һәм Программаны гамәлгә ашыру чорына булган ихтыяҗлар дәрәҗәсендә сакларга мөмкинлек бирәчәк.

Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге, чараларны Казан шәһәре муниципаль бюджеты акчалары һәм бюджеттан тыш акчалар хисабына финанслау әлеге Программа кушымтасында китерелә.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2026-2028 еллар.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалануны күздә тота.

| Ел | Акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты** | **Татарстан Республикасы бюджеты** |
| 2026 | 343 885,2 | - |
| 2027 | 269 856,6 | - |
| 2028 | 269 856,6 | - |
| **БАРЛЫГЫ** | 883 598,4 | **-** |

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында, бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, аларга ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Программа белән идарә итү механизмын үз эченә алган Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның төп чаралары 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль закон нигезендә муниципаль заказ башкаручыны билгеләү буенча конкурс процедураларын уздыру нигезендә гамәлгә ашырылачак. Муниципаль заказны башкаручы белән муниципаль контрактлар төзеләчәк. Эшләрне башкару этаплары, чараларны үтәү вакыты, түләү тәртибе муниципаль контракт нигезендә билгеләнәчәк. Конкурс процедураларын үткәрүдән тыш, бердәнбер тәэминатчы белән төзелгән муниципаль контракт нигезендә башкарылучы хезмәтләр һәм эшләр дә бар (базарда монополия хәлендә булган оешмалар башкара торган хезмәтләр һәм эшләр). Мондый контрактларны төзү шартлары югарыда күрсәтелгән федераль закон белән төгәл билгеләнгән.

Программа чараларын гамәлгә ашыру кысаларында шәһәр бюджеты акчаларын куллануны контрольдә тоту бюджет законнары һәм 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль закон буенча муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендәге законнар нигезендә башкарыла.

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында муниципаль заказ бирүче чараларны башкаруның барышын тикшереп тора һәм акчаларны нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә.

Муниципаль заказ бирүче

- Программа чаралары кысаларында башкаручының структур бүлекчәләренең гамәлләрен координацияләүне тәэмин итә;

- Программаның бурычларын гамәлгә ашырганда иң алдынгы һәм фәнгә нигезләнгән чишелешләрне сынап карый һәм кертә;

- «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесен гамәлгә куючының уставы нигезендә аның функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итә;

- «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә консультатив, методик, хокукый ярдәм күрсәтә;

- «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлеген координацияли, кирәк булганда аның эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертә;

- квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 20 нче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә карарның 2 номерлы кушымтасындагы форма буенча Программаны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат җибәрә;

- ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүматны, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат бирә.

## V. Программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләренең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм аларны тасвирлау

Программаны гамәлгә ашыруның төп социаль-икътисади нәтиҗәсе:

- Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль яктан әһәмиятле объектларында куркынычсызлык таләпләрен тәэмин итү, Казан шәһәре территориясендә җәмәгать куркынычсызлыгының дәрәҗәсен арттыру;

- Әлеге Программаны гамәлгә ашыру өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге Программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

«2026-2028 елларга “Имин шәһәр” аппарат-программа комплексы сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасына кушымта

**Программаның максатлары, бурычлары, төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау**

| Төп чараларның атамалары | Башкаручы | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторла-ры, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 (база елы) | 2026 | 2027 | 2028 | 2026 | 2027 | 2028 |
| Максат: җәмәгать куркынычсызлыгының, хокук тәртибенең һәм яшәү тирәлеге куркынычсызлыгының гомуми дәрәҗәсен арттыру | | | | | | | | | | |
| Бурыч: муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында, Казан шәһәренең җәмәгать киңлекләрендә, паркларда һәм скверларда, җәмәгать фикерен белдерү урыннарында куркынычсызлык системаларын оештырганда заманча мәгълүмат технологияләрен кертү | | | | | | | | | | |
| 1. Җәмәгать киңлекләрендә, паркларда, скверларда һәм җәмәгатьчелек фикерен белдерү урыннарында видеокүзәтү системасын үстерү һәм куркынычсызлык-ны арттыру | «Телекоммуни-кация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026-2028 | Видеокүзәтү системаларына хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау каралган объектлар өлеше (%) | 98 | 98 | 98 | 98 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 32 265,4 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 16 281,4 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 16 281,4 |
| | | | Куркынычсыз-лык системаларына хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | 98 | 98 | 98 | 98 | | | |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручы** | **Төп чара-ларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторла-ры, үлчәү берәмлекләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сум** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2025 (база елы)** | **2026** | **2027** | **2028** | **2026** | **2027** | **2028** |
| | | | каралган объектлар өлеше (%) | | | | | | | |
| 2. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында видеокүзәтүнең үсеше | «Телекомму-никация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026-2028 | Видеокүзәтү системалары белән җиһазланган социаль өлкә объектлары өлеше (%) | 98 | 98 | 98 | 98 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 106 529,7 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 108 018,5 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 108 018,5 |
| 3. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында куркынычсызлык-ны арттыру | «Телекомму-никация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026-2028 | Автомат янгын сигнализация-се, хәбәр итү һәм эвакуация белән идарә итү буенча ремонтланган һәм модернизация-ләнгән системалар белән җиһазланган социаль өлкә объектлары өлеше (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 136 234,7 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 134 745,9 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 134 745,9 |

| Төп чараларның атамалары | Башкаручы | Төп чара-ларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторла-ры, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 (база елы) | 2026 | 2027 | 2028 | 2026 | 2027 | 2028 |
| 4. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында мәгълүмат чыганакларының һәм куркынычсызлык системаларының техник торышын мониторинглау, ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру | «Телекомму-никация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026-2028 | Социаль өлкә объектларында куркынычсыз-лыкны тәэмин итү системалары белән җиһазландыру өлеше (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 1 327,00 | Казан шәһәре МБ бюджеты — 1 327,00 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 1 327,00 |
| 5. Казан шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы административ биналарда куркынычсызлык системаларын оештыру һәм аларга техник хезмәт күрсәтү | «Телекомму-никация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026-2028 | Казан шәһәре Башкарма комитетының административ биналары иминлеген тәэмин итү системалары белән җиһазландыру өлеше (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 0 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 0 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 0 |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручы** | **Төп чара-ларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторла-ры, үлчәү берәмлекләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сум** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2025 (база елы)** | **2026** | **2027** | **2028** | **2026** | **2027** | **2028** |
| 6. «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе, «Телекомму-никация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026-2028 | «Телекомму-никация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе-нең, ихтыяҗларның гомуми дәрәҗәсеннән чыгып, матди-техник тәэмин ителеш дәрәҗәсе (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 67 528,4 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 9 483,8 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 9 483,8 |
| | | | Телекоммуни-кация технологияләре департаменты-ның, штат санынан чыгып, кадрлар белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе (%) | 98 | 98 | 98 | 98 | | | |
| | | | «Телекоммуни кация технологияләре | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручы** | **Төп чара-ларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторла-ры, үлчәү берәмлекләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сум** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2025 (база елы)** | **2026** | **2027** | **2028** | **2026** | **2027** | **2028** |
| | | | департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлеген, аның финанс-хуҗалык эшчәнлеге планыннан чыгып, финанс белән тәэмин итү дәрәҗәсе (%) | | | | | | | |
| Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына барлыгы | | | | | | | | 343 885,2 | 269 856,6 | 269 856,6 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына барлыгы | | | | | | | | 0 | - | - |
| Барлыгы | | | | | | | | 343 885,2 | 269 856,6 | 269 856,6 |

Кабул ителгән кыскартулар:

- Казан шәһәре МБ бюджеты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;

- «Телекоммуникация технологияләре департаменты» МБУ – «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе.